**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ УЛЬЯНОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**УЛЬЯНОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423115, Ульяновка село, Центральная ул., 44 дом тел./факс+7(84396) 2-33-16/2-33-17 email: Ul.Cmn2@tatar.ru 423115, Ульяновка авылы, Үзэк урамы, 44 йорт

30.04.2021 №10

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 31 мартында кабул ителгән «2020 елда Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 174 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләр турында» 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елның 30 апрелендәге 10 номерлы карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «2020,2021 һәм аннан соңгы елларга Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында»;
2. Карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлегенең 2020, 2021 һәм аннан соңгы елларга салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен расларга».
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

ТР Чирмешән муниципаль районы
Ульяновка авыл җирлеге
Башкарма комитеты
җитәкчесе урынбасары М.Г. Матросова